# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең
Мортыш -Тамак торак пунктында
2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**29.11.2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең Мортыш-Тамак торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең Мортыш -Тамак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2024 елда 2000 сум күләмендә үзсалым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, армиядә хезмәт итүчеләр, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

*1) Мортыш Тамак торак пунктында юл кырыен чаптыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);*

*2) Мортыш Тамак торак пункты янындагы чишмәне төзекләндерү (материаллар сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).*

3. Җыенның нәтиҗәләрен Кәдрәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән, халык җыенының нәтиҗәләрен Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга(https://menzelinsk.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән соң ун көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Кадрәк авыл җирлеге башлыгы ____________ Х. Х. Нәбиуллин
(имза)